**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ КЫЯЗЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

№ 15 25.01.2016 ел

**Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы башлыгының 2015 елда социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2016 елга фараз турында хисабы.**

Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы башлыгының 2015 елгы социаль – икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2016 елга фараз турындагы хисабын тыңлап һәм фикер алышып. Депутатлар билгеләп үткәнчә, авыл җирлеге Советы эшчәнлеге 2015 елда авыл җирлеге халкы мәнфәгатьләрендә, «РФда җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең 6.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Законы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы карары:

1. Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы башлыгы И.м. Заһидуллинның 2015 елда авыл җирлегенең социаль – икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2016 елга фараз турында хисабын игътибарга алырга.
2. 2016 елда авыл җирлеген социаль – икътисади үстерүнең төп бурычы булып халыкның тормыш сыйфаты үсешен тәэмин итү санала.
3. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирергә.
4. Кредитлау һәм торак төзелеше өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган программаларның мөмкинлекләрен авылда яшьләрне ныгыту өчен максималь файдалану.
5. Халыкның тормыш дәрәҗәсен төшерүгә юл куймау һәм гражданнарның социаль хезмәтләргә тигез керү мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар күрергә.
6. Хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать иминлеге дәрәҗәсен күтәрү һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген һәм дәрәҗәсен ышанычлырак яклауны тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга.
7. Торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә.

8. Авыл җирлеге башкарма комитетына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә тәкъдим итәргә.

9. Авыл җирлеге Советы аппаратына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә.

10. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http:aksubaevo.tatarstan.ru.

11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе: И. М. Заһидуллин